**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

Бөгелмә районының Подлесный поселогындагы Яңа урам;

Саба районының Курсабаш авылындагы Мәктәп урамы;

«Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе Юртово участок урманчылыгының 152 нче кварталында урнашкан «Кояшкай» шәһәр яны лагере территориясе.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2016 елның 6 февралендәге ПУ-110 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 12 апрель
№ ПУ-338